СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«15» ноябрь 2021 г.

**КАРАР**
№ 36

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендә кабул ителгән 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236 Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының 21.10.2019 ел, №108 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү:

1.1. 1.7 пункт. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга) pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы — Р.Ф.Габдрахманов